Гимназиянең фәнни-методик киңәшмә
утырышында каралды
Протокол №3, 15 гыйнвар 2021 ел

Раслыйм
ГБМБУ "90 нчы гимназия" директоры
_____________/ Г.Д. Закирҗанова
Приказ №12, «18»гыйнвар 2021ел.

**Казан шәһәре Совет районы**

**гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе**

**"90 нчы гимназия"нең**

# "Рухи хәзинә" проекты

Проект 2021-2025 нче елларга планлаштырыла

Төзүчеләр: Сәлахова И.Ә.,Габделхакова Г.Р.
югары квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучылары

Казан, 2021

**Проект турында.**

Бүгенге көн яшәешебездә яшь буында милли үзаң тәрбияләү һәм әхлак сыйфатлары булдыру мәсьәләләре кискен тора. Һәр милләт үзен ничек саклап кала ала? Үз милләте белән горурлана белүче, югары әхлак сыйфатларына ия булган шәхесләрне ничек тәрбияләргә? Бу өлкәдә эшчәнлекне ничек оештырырга? Билгеле, эшне кечкенәдән үк башлау, мәктәп чорында дәвам итү, гаилә белән берлектә алып бару зарур. Милли үзаң үз телеңне, үз халкыңны ярата белүдән башлана. Халкыңны ярату, аның белән горурлану өчен аның рухи хәзинәсен, үткәнен, бүгенгесен белү кирәк. Бу очракта һәр халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен, күңел байлыгын чагылдырган гореф-гадәтләргә, традицияләргә, әдәби хәзинәләргә, тел-сөйләм чараларына таяну тәрбиянең нигезе булып тора. Күп гасырлар дәвамында буыннан-буынга тапшырылып килгән, ләкин бүгенге көндә онытылып барган рухи мирасыбыз белән яшь буынны таныштыру, аның матур үрнәкләрен тәкъдим итү аша күңелләренә матурлык, чисталык орлыклары салу тәрбия эшчәнлегенең асылын тәшкил итә. Мәгариф системасы эшчәнлегендә белем бирү белән беррәттән милли үзаңга, әхлакка ия балалар тәрбияләү мәсьәләсе үз югарылыгында оештырылганда, киләчәктә татар милләте дә башка милләтләр дә яшәячәк һәм алар арасында дуслык булачак. “Рухи хәзинә” проектына шушы юнәлешне күз алдында тотып нигез салынды. Совет районы ГБМБУ “90 нчы гимназия” дә күп төрле милләт вәкилләренең балалары белем ала. Татар, рус, мари, удмурт, әзербәйҗан, үзбәк, таҗик, пуштун милләтеннән булган балалар бар. Һәрбер милләт баласының үз халкының рухи мирасын өйрәнеп үсәргә хакы бар. “Рухи хәзинә” проекты укучыларда үз халкына, үз милләтенә карата кызыксыну уята. Гимназиядә укучы һәрбер милләт баласына үз милләтенең үткәндәге яшәешен, бүгенге тормышын, гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен, күңел байлыгын, рухи кыйммәтләрен төрле яклап өйрәнергә мөмкинлек бирә.

**Проектның актуальлеге.**

Белем һәм тәрбия алып, мәктәпне тәмамлаучы бүгенге заман укучылары нинди сыйфатларга ия? Алар олы тормыш юлына әзерме? Мәгариф системасы белем бирүгә күбрәк басым ясап, милли тәрбия, әхлаклылык кебек яшәешебез өчен бик тә мөһим булган мәсьәләләргә игътибарны киметмиме? Бу сорау киләчәгебез турында борчылган, аны кайгырткан һәркемне уйландырырга тиеш. Бүгенге көн әти-әниләре дә, укучылар да әлеге проблемага җитди карамый. Әти-әниләр үз балаларын тормышта замана шартларында югалып калмастай, конкурентлылыкка сәләтле, БДИ ны яхшы балларга биреп, яхшы югары уку йортларына керә алырдай итеп үстерерү максатын куя. Мәгариф системасы да әлеге максатка хезмәт итә. Тәрбия мәсьәләсенә караганда белем бирүгә күбрәк басым ясала. Бик тә белемле, ләкин халыкларга хөрмәте булмаган, әхлаксыз балаларны тормышка чыгарсак, яшәешебезнең киләчәге нинди булыр? Моңа бәйле рәвештә, бүгенге көндә яшәешебез өчен бик тә кыйммәтле милли үзаң һәм әхлак проблемалары көнүзәк мәсьәләләрнең берсе булып калкып чыга.

Укучыларда милли үзаң тәрбияләү проблемасын ТР мәгариф һәм фән министры И. Г. Һадиуллин “Татар информ” агентлыгына биргән интервьюсында  соңгы еллардагы иң мөһим мәсьәләләрнең берсе дип атый. Бу мәсьәлә буенча эшчәнлекне арттыруны күздә тота. Димәк, тәрбия мәсьәләсе белем бирү эшчәнлеге  белән бертигез дәрәҗәгә күтәрелер, дигән өмет бар. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов 2021 нче елны Татарстан республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итте. Алдагы елларда барлык милләтләргә, барлык телләргә игътибар артыр, дигән өмет туа.

Туган тел укытучылары алдында милли үзаң тәрбияләү бурычы җитди проблема булып тора. Бүгенге көн вәзгыятендәге төрле илләр, халыклар,  милләтләр арасындагы каршылыкларга игътибар итсәк, бу проблемадан чыгуның төп юлы милләтләр арасында дуслык булдыру, бер-берсенә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү кирәклеге ачык чагыла.  Бүгенге көн укучысы тормыш итәргә әзерлекле, шул ук вакытта  белемле, үз тарихына, үз теленә, үз гореф-гадәтләренә сакчыл карашлы, башка милләтләргә хөрмәт белән карый торган булып үсәргә тиеш. Бу хакта тирәнрәк уйласак,  “Рухи хәзинә” проектының бүгенге көндә ни дәрәҗәдә актуаль булуы яхшы аңлашыла. Бигрәк тә, күп төрле милләт вәкилләренең балалары: татар, рус, мари, удмурт, әзербәйҗан, үзбәк, таҗик, пуштун милләтеннән булган балалар белем алган   Совет районы ГБМБУ “90 нчы гимназия” дә укучыларда үз милләтенә, үз теленә уңай караш булырга, һәр бала үз милләте белән горурланырга һәм милләтләр дуслыгы яшәргә тиеш.

**Проектның максатлары һәм бурычлары.**

Һәр халык үзенең традицияләрен, борынгыдан килгән яшәү рәвешен сакларга тырыша. Бу эш рухи кыйммәтләр өлкәннәрдән яшь буынга тапшырылса гына трмышка  аша ала. Шул уңайдан балаларның борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, нәселдән бирелә торган гаилә кыйммәтләренә мөнәсәбәтләрен белү максатыннан,гимназиянең 5-6 нчы сыйныф укучылары арасында тикшеренү эше узды. Сорауларга җавап бирү аша түбәндәге нәтиҗәләр күзәтелде:

– үз халкының борынгыдан килгән гореф-гадәтләре турында 21% укучы гына нәрсәдер белә һәм бу хакта уйлана;

–35% укучы гаиләдә  әдәп-әхлак кагыйдәләре турында ишетеп  белә;

– нәселдән бирелә торган гаилә кыйммәтләре турында 18% укучы хәбәрдар;

-98 % укучы барлык милләтләр дә сакланырга һәм дус яшәргә тиеш, дип саный.

Тикшеренүләр нәтиҗәсеннән, күренгән проблемалардан чыгып, **“Рухи хәзинә” проекты түбәндәге максатны куя:**

- Тормыш итәргә әзерлекле,  белемле, үз тарихына, үз теленә, үз гореф-гадәтләренә сакчыл карашлы, башка милләтләргә хөрмәт белән карый торган  укучылар тәрбияләү.

**Проектның бурычлары:**

- укучыларда милли үзаң булдыру, аның дәрәҗәсен үстерү; үз халкына, аның рухи кыйммәтләренә битараф булмаска кирәклегенә төшендерү;

- һәрбер милләт баласында үз халкы белән горурлану, патриотизм хисләре булдыру; халыкларның рухи мирасын өйрәнү аша туган илгә, туган җиргә, халыкка, туган телгә мәхәббәт хисләре булган, һәряклы үсешкә ирешкән шәхес тәрбияләү;

- укучыларга  әхлаклак тәрбисе бирү; мәрхәмәтлелек, әдәплелек, төгәллек, шәфкатьлелек ,олыларга һәм кечеләргә хөрмәт, барлык кешеләргә ихтирам кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү;

- этнокультура булдыру;

- милли гореф-гадәтләрне сакларга өйрәнү;

- укучыларга милләтне саклап калуның мөһимлеген аңлату;

**Проектның төп эчтәлеге.**

Проект эшчәнлегенең форма һәм методлары:

- дәрестән тыш эшчәнлекнең үзенчәлекле формаларында уеннар;

- экскурсияләр;

- эзләнү эшләре; викториналар;

- проектлар төзү һәм яклау;

- әти-әниләр катнашында мастер- класслар;

- күренекле шәхесләр белән очрашулар;

- стена гәҗитләре, күргәзмәләр, модельләштерү эшләре эшләү;

**Проект эшчәнлеге 2 юнәлештә алып барырга планлаштыла:**

1. **Беренче юнәлеш.** Төрле халыкларының телләре, гореф-гадәтләре, киемнәре, әдәбияты, аш-су серләре, яшәешләре турында укучылар белән берлектә материаллар туплау, видеоязмалар яздыру, интерактив дәресләр булдыру. Проектор экраны аша  язмаларны тәнәфесләрдә, дәресләрдә карау мөмкинлеге булдыру.

Бу юнәлеш буенча түбәндәге эшләр планлаштырыла:

- “Идел буе халыкларының милли киемнәре” экспозициясен булдыру;

- Гимназиядә эшләп килүче “Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары” музей экспозициясен тулыландыру;

- “Идел буе халыкларының милли киемнәре” һәм “Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары” экспозицияләре ярдәмендә музей дәресләре оештыру;

- “Идел буе халыкларының милли киемнәре” һәм “Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары” экспозицияләре өчен укучылардан экскурсоводлар әзерләү;

- “Экскурсоводлар әзерләү” проектын булдыру;

- декоратив-гамәли сәнгать, халык һөнәрләре, биюләре, халык җырлары, уеннары, фольклорның төрле жанрлары турында мәгълүматлар туплау, аларны системага салу;

- “Милли бизәкләрнең серләре” темасына проект эшләре эшләү;

- “Идел буе халыкларның бәйрәмнәре” темасына презентацияләр ясау;

-Татар халкының йолалары (туй йоласы, хезмәт йоласы, милли бәйрәмнәр, дини бәйрәмнәр, солдат озату йоласы, каз өмәсе һ.б.) темасына проектлар эшләү;

- һәрбер милләт баласында үз халкы белән горурлану, патриотизм хисләре булдыру максатыннан, “Туган илемне, туган җиремне, туган халкымны, туган телемне яратам!” темасына иншалар бәйгесе үткәрү;

- Халыклар дуслыгы темасына “Сөйләшсәк тә төрле телләрдә” бәйгесен үткәрү;

- “Халыклар дуслыгы- Җирнең тынычлыгы” проекты эшчәнлеге.

**2. Икенче юнәлеш.** Укучыларга әхлаклак тәрбисе бирү аша мәрхәмәтлелек, әдәплелек, төгәллек, шәфкатьлеле,олыларга һәм кечеләргә хөрмәт, барлык кешеләргә ихтирам кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү.

Бу юнәлеш буенча түбәндәге эшләр планлаштырыла:

- “Күркәм тәрбия” дәрестән тыш эшчәнлек программасын булдыру;
- “Күркәм тәрбия” дәрестән тыш эшчәнлек программасына нигезләнеп, әхлак дәресләре үткәрү; укучыларга әхлаклак тәрбисе бирү;
- “Күркәм тәрбия” дәрестән тыш эшчәнлек программасына нигезләнеп, әти-әниләр белән эшчәнлекне оештыру;
- Милләтебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын барлап, “Татар халкына хас, мин дә ия булырга тиешле сыйфатлар” дип исемләнгән интерактив китап төзү. Проект эшчәнлеге гимназиянең “Мәгълүмат интерактив тактасы” аша укучыларга, укытучыларга, әти-әниләргә яттыртылачак. Укучылар тәнәфестә, дәрестән тыш эшчәнлек вакытында, ял вакытларында “Мәгълүмат интерактив тактасы”ннан үзләрен кызыксындырган темаларга материалларны табып, таныша алачак. Яңалыклар интернет челтәрендә, гимназиянең Instagram дагы аккаунтында да урын алачак.

**Ресурслар.**

-гимназиядәге экспозицияләр;

- интерактив такта; матди-техник база;

-кадрлар (укучылар, оештыручы укытучы- җитәкче, әти-әниләр)

- татар теле һәм әдәбияты кабинеты;

- интернет челтәре;

- театрлар;

- парклар;

- Казан шәһәренең тәрбия һәм белем картасы.

**Максатчан аудитория.**

“Рухи хәзинә” проекты ГБМБУ “90 нчы гимназия” нең укучылары эшчәнлегенә нигезләнә, барлык укучыларның да катнашуы күзаллана. Проект эчтәлеге укучыларны пассив тыңлаучы итеп түгел, бәлки чараларда актив катнашучы, эзләнүче, еш кына оештыручы буларак эшчәнлеген алга куя, бу исә аларда уңай, күркәм сыйфатлар тәрбияләргә, актив гражданин булырга җирлек тудыра. “Рухи хәзинә” проекты укучыларның яшь һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, дәвамчанлыкка таянып төзелә. Бу исә эшчәнлекнең нәтиҗәсен ачык күзалларга һәм куелган максатка ирешү юлын билгеләргә мөмкинлек бирә.Проект укучыларның башлангыч сыйныфлардан алып, чыгарылыш сыйныфларга кадәр эшчәнлеген күзаллый. Проект эшенә ата-аналарны да тарту планлаштырыла. Сыйныф җитәкчеләренең, гимназия директорының тәрбия эшләре буенча урынбасарының вазифалары билгеләнә. Укытучы оештыручы вазифасын башкара.

**Проектны тормышка ашыру планы.**

**Проект өчен кирәкле җиһазлар, материаллар:**

| **Кирәкле җиһазлар, материаллар** | **Бар** | **Булдырырга кирәк** |
|---|---|---|
| Ноутбук, микрофон | | + |
| Проектор | + | |
| Экспозицияләр төзү өчен милли киемнәр, маникеннар, заманча эшләнгән пыяла витриналар | - | Булдырырга кирәк:<br>-маникеннар;<br>-төрле милләтләрнең милли киемнәре;<br>-татар халкының һәм башка |

| | | |
|---|---|---|
| | | халыкларның тормыш-көнкүрештә кирәкле әйберләре. |
| Китап төзү өчен программа | | + |
| Интерактив дәресләр, язмаларны булдырып, системага салу, проектта катнашучыларга тәкъдим итү өчен интерактив такта. | + | |

**Проектны тормышка ашыру планы, этаплары.**

| **Планлаштырылган эшләр** | **Җаваплы** | **Вакыты** |
|---|---|---|
| **Беренче юнәлеш буенча эшчәнлек** | | |
| Төрле халыкларының телләре, гореф-гадәтләре, киемнәре, әдәбияты, аш-су серләре, яшәешләре турында укучылар белән берлектә материаллар туплау, | 2-11 сыйныф укучылары | 2021 нче ел, гыйнвар- ноябрь **(планлаштыру, әзерлек чоры)** |
| Төрле халыкларының телләре, гореф-гадәтләре, киемнәре, әдәбияты, аш-су серләре, яшәешләре турында видеоязмалар яздыру. | 2-11 сыйныф укучылары | 2021 нче ел гыйнвар- ноябрь **(даими эшчәнлек)** |
| Төрле халыкларының телләре, гореф-гадәтләре, киемнәре, әдәбияты, аш-су серләре, яшәешләре турында интерактив дәресләр булдыру. | Проект җитәкчесе һәм укучылар | 2021 нче ел гыйнвар- ноябрь **(даими эшчәнлек)** |
| Проектор экраны аша язмаларны тәнәфесләрдә, дәресләрдә карау | | 2021 нче ел **(даими эшчәнлек)** |
| Гимназиядә эшләп килүче “Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары” музей экспозициясен тулыландыру; | проект җитәкчесе, укучылар, ата-аналар | 2021 нче ел Гыйнвар-май |
| “Идел буе халыкларының милли киемнәре” экспозициясен булдыру; | проект җитәкчесе, укучылар, ата-аналар | 2021 нче ел, гыйнвар-март |
| “Экскурсоводлар әзерләү” проектын булдыру; | проект җитәкчесе | 2021 нче ел, гыйнвар |
| “Идел буе халыкларының милли киемнәре” һәм “Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк- | проект җитәкчесе, туган тел фәнен | 2021 нче ел, гыйнвар-февраль |

| | | |
|---|---|---|
| яраклары” экспозицияләре өчен укучылардан экскурсоводлар әзерләү. | укытучылар | |
| “Идел буе халыкларының милли киемнәре” һәм “Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары” экспозицияләре ярдәмендә музей дәресләр оештыру; | укучылар | 2021 нче ел гыйнвар- ноябрь **(даими эшчәнлек)** |
| декоратив-гамәли сәнгать, халык һөнәрләре, биюләре, халык җырлары, уеннары, фольклорның төрле жанрлары турында мәгълүматлар туплау, аларны системага салу; | Проект җитәкчесе һәм укучылар | 2021-2025 нче ел **(даими эшчәнлек)** |
| Милли бизәкләрнең серләре” темасына проект эшләре эшләү; проектларны яклау. | Укучылар, ата-аналар | 2021-2022 нче еллар |
| Идел буе халыкларның бәйрәмнәре” темасына презентацияләр ясау; | 9- 11 сыйныф укучылары | 2021 нче ел |
| Татар халкының йолалары (туй йоласы, кезмәт йоласы, милли бәйрәмнәр, дини бәйрәмнәр, солдат озату йоласы, каз өмәсе һ.б.) темасына проектлар эшләү; | 7- 8 сыйныф укучылары | 2021 нче ел |
| һәрбер милләт баласында үз халкы белән горурлану, патриотизм хисләре булдыру максатыннан, “Туган илемне, туган җиремне, туган халкымны, туган телемне яратам!” темасына иншалар бәйгесе үткәрү; | Башлангыч сыйныф укучылары | 2021 нче ел. апрель |
| Халыклар дуслыгы темасына “Сөйләшсәк тә төрле телләрдә” бәйгесен үткәрү; | 1-11 сыйныф укучылары | 2021 нче ел. февраль |
| Халыклар дуслыгы- Җирнең тынычлыгы” проекты эшчәнлеге. | 1-10 сыйныф укучылары | 2022 нче ел. ноябрь |
| Театрларга, музейларга йөрү. Музейлар белән берлектә материал туплау. | проект җитәкчесе, укучылар, ата-аналар | 2021-2025 нче еллар, ( **даими)** |
| **Беренче юнәлеш буенча эшчәнлек** | | |
| “Күркәм тәрбия” дәрестән тыш эшчәнлек программасын булдыру; | Проект җитәкчесе | 2021 нче ел, февраль-март |
| “Күркәм тәрбия” дәрестән тыш эшчәнлек программасына нигезләнеп, әхлак дәресләре | Проект җитәкчесе, укытучылар, | 2021-2022 нче еллар |

| | | |
|---|---|---|
| үткәрү; укучыларга әхлаклак тәрбисе бирү; | сыйныф җитәкчеләре | |
| “Күркәм тәрбия” дәрестән тыш эшчәнлек программасына нигезләнеп, әти-әниләр белән эшчәнлекне оештыру; | Проект җитәкчесе, сыйныф җитәкчеләре | 2021 нче ел. (**даими)** |
| Милләтебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын барлап, “Татар халкына хас әхлакый сыйфатлар” дип исемләнгән интерактив китап төзү. | 1-11 сыйныф укучылары берлектә | 2021-2022 нче еллар |
| Ризаэтдин Фәхретдин, Каюм Насыйри мирасларын өйрәнү. | Проект җитәкчесе һәм укучылар | 2021-2025 нче еллар, ( **даими)** |
| “Мәгълүмат интерактив тактасы” аша укучыларга, укытучыларга, әти-әниләргә тупланган материалны тәкъдим итү. | Проект җитәкчесе һәм укучылар | 2021-2025 нче еллар, ( **даими)** |
| Әхлак темасына проектлар төзү. Проектларны яклау. | 8-10 сыйныф укучылары | 2021 нче ел. **(апрель-май)** |
| “Рухи хәзинә” пректы эшчәнлегенә анализ | Проект җитәкчесе | 2021-2025 еллар **Һәр елны апрель ае** |

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм социаль эффект** .

**Программа эшчәнлеге буенча көтелгән нәтиҗәләр:**
**Шәхси нәтиҗәләр:**

- киләчәк тормышка әзерлекле булу;

- киләчәктә милләтне саклардай, һәркемгә үрнәк булырдай милли җанлы булып үсү;

- милли гореф-гадәтләрне белү, аларны сакларга өйрәнү;

- әхлаклы һәм акыллы, кешеләрне хөрмәт итә белә торган балалар үстерү өчен, әлеге сыйфатларның үзеңдә булырга тиешлеген аңлауга ирешү;

- әхлак кагыйдәләренең яшәешнең нигезе һәм бәхетле киләчәге булуын аңлау;

- әхлак кагыйдәләренең милли-мәдәни кыйммәт булуын, җәмгыятьтәге урынын аңлау; ата-ана, туганнарның кадерен белү, хөрмәтләү, ярату, аларга ярдәмчел булу;

- туган телгә, туган илгә, үз халкыңа мәхәббәтле булу, аның белән горурлану, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләү;

- туган телдә аралашу, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык итеп әйтә белү;

- мәктәптә, өйдә, җәмгыятьтә үзеңне дөрес тоту;

- үз-үзеңне тәрбияләү буенча һәрдаим шөгыльләнү;

**Предметара нәтиҗәләр:**

- әхлак кагыйдәләренең фәннәрне өйрәнү һәм белем алуда ярдәм итүен аңлау;

- әхлак кагыйдәләрен тел, мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү;

- үз туган телеңне белеп һәм саклап, рус телен һәм башка телләрне хөрмәт итү, өйрәнү, телләр һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә – рухи кыйммәтләргә ихтирамлы, башка милләт вәкилләренә карата түземле-ихтибарлы мөнәсәбәттә булу; - әхлак кагыйдәләрен тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, аның үсеше турында күзаллау формалаштыру, җәмгыять үсеше һәм әхлакның турыдан-туры мөнәсәбәте булуын аңлау;

**“Рухи хәзинә” проектын тормышка ашыруда барлыкка килгән төп нәтиҗәләр:**

- Укучыларга тәнәфесләрдә, дәресләрдә, ял вакытларында, дәрестән тыш эшчәнлек вакытында “Мәгълүмат интерактив тактасы” проектор экраны аша мәгълүмат алыр өчен төрле халыкларының, бигрәк тә татар халкының теле, гореф-гадәтләре, киемнәре, әдәбияты, аш-су серләре, яшәешләре турында язмалар булдыру.
- Тупланган язмалардан “Рухи хәзинә” проект эшчәнлегендә киләчәктә кулланырдай (укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, 1-11 сыйныфлар өчен), милли кыйммәтләрнең һәркайсы турында мәгълүмат бирердәй “Рухи хәзинәләр” интерактив дәресләр системасын булдыру.
- Укучыларның тормыш итәргә әзерлекле, белемле, үз тарихына, үз теленә, үз гореф-гадәтләренә сакчыл карашлы, башка милләтләргә хөрмәт белән карый торган булуларына ирешү.
- “Күркәм тәрбия” дәрестән тыш эшчәнлек программасын төзү.
- Милләтебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын барлап, “Татар халкына хас әхлакый сыйфатлар” дип исемләнгән интерактив китап булдыру.

**Проектның киләчәк үсеше перспективалары.**


“Рухи хәзинә” проектының **яңалыгы** шунда, ул һәр милләт баласын үз халкының тарихы, теле, яшәеше турында уйланырга мәҗбүр итә, һәрбер милләткә хөрмәт белән карарга кирәклеген төшендерә. Проект музей экспозицияләрендә булган иске экспонатларны үз куллары белән тотып карап, төрле халыклар турында мәгълүматларны заманча проект технологияләре ярдәмендә үзләре эзләп табып, өйрәнеп, анализлап, аларны заманча дәресләр, күргәзмәләр, язмалар аша системага салып өйрәнү мөмкинлеге бирә. Музей дәресләре аша тәрбия алырга мөмкинлек тудыра.

Проект **дәвамлы** булуны таләп итә. Кыска вакыт аралыгында тормыш итәргә әзерлекле, белемле, үз тарихына, үз теленә, үз гореф-гадәтләренә сакчыл карашлы, башка милләтләргә хөрмәт белән карый торган укучылар тәрбияләү мөмкин түгел. Бу эш- күп көч һәм вакыт таләп итә. **Проект 2021-2025 нче елларга исәпләнә.** Шушы еллар аралыгында проектта катнашучылар тарафыннан рухи кыйммәтләребез, әдәп-әхлак кагыйдәләребез турында күп кенә материал тупланыр, һәрбер милләт баласы үз халкының рухи кыйммәтләрен белер, аларга хөрмәт белән карарга өйрәнер, дип ышанасы килә. “Рухи хәзинә” проекты милләтләр арасында дуслыкка, аңлашып яшәргә өйрәтә. Әлеге проектка барлык мәктәпләр кушылса, Җир шарында дуслык, татулык ныгыр, әхлаклылык артыр, халыклар арасында яхшы мөнәсәбәт барлыкка килер.

*Кушымта.*

# Проект эшчәнлеге.

**ВМК. Мәскәү. Литвиненко Наташа-җиңүче.**













РАНХиГС
Российская академия народного хозяйства и государственной службы при Президенте Российской Федерации

ФИРО
Федеральный институт развития образования

СЕРТИФИКАТ

участника очного этапа мероприятия «Всероссийский мастер-класс учителей родного, в том числе русского, языка – 2019» по направлению «Конкурс творчества учащихся на родном языке, в том числе русском», проводимого на конкурсной основе в Федеральном государственном бюджетном образовательном учреждении высшего образования «Российская академия народного хозяйства и государственной службы при Президенте Российской Федерации»

**Литвиненко Наталья Игоревна**

ученица МБОУ «Гимназия 90» г. Казани
Республики Татарстан

Директор ФИРО РАНХиГС М.В. Дулинов

РАНХиГС
12–15 ноября 2019 г.



ДИПЛОМ

награждается

***Литвиненко Наталья Игоревна***

ученица МБОУ "Гимназия 90" г.Казани
Республики Татарстан

*Победитель Всероссийского мастер-класса учителей родного, в том числе русского, языка в направлении «Конкурс творчества учащихся на родном языке, в том числе русском» в номинации*
***«Литературное творчество на родном, включая русский, языке»***

Директор
ФИРО РАНХиГС Дулинов М.В.

ноября 2019 г.
Москва

**ВМК-2021 Мәскәү . “Укытучы-яңалык кертүче” номинациясендә җиңүче.**



























**“Мин бит татар малае”  һәм  “Татар кызы. Татар егете” бәйгеләре.**



















**“Әдәби җомга” очрашулары**
















**“Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары” музей экспозициясе**







| | |
|---|---|
|  |  |
| **Татар халкының тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары”. Музей дәресләре.** | |
|  |  |
| **“Экскурсоводлар” проекты.** | |
|  |  |
|  |  |

**“Милли бизәкләрнең серләре” проекты**














МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ДИПЛОМ
I степени

Республиканская проектная
и исследовательская конференция школьников
«Интеллект. Культура. Карьера»

Секция Прикладного творчества

вручается

Салиховой Камиле, Фаттаховой Алине, Мингалеевой Камилле

Научный руководитель: Салахова И.А
Даутова Л.Р.

Заместитель министра
образования и науки
Республики Татарстан М. З. Закирова

2021 год

**“Халык йолалары” проекты**

**Идел буе халыкларының туй йолалары**

Рус халкы туе



Башкорт туе



Мари туе



Чуваш туе



Татар туе



Мордва туе



Удмурт туе





Министерство образования и науки Республики Татарстан
Академия наук Республики Татарстан
Всероссийский конкурс юношеских исследовательских работ им. В. И. Вернадского
Татарстанское республиканское отделение Межрегионального
общественного движения творческих педагогов "Исследователь"
Центр повышения квалификации АН РТ

ДИПЛОМ

ЛАУРЕАТА

регионального конкурса исследовательских работ обучающихся 8-11классов

"ИССЛЕДОВАТЕЛЬ"

вручается

Ярославцеву Савелию

с работой на тему:

«Свадебные традиции народов Поволжья»

Научный руководитель: Салахова Илюса Адиповна, учитель татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия №90»

М. Х. Салахов
президент Академии наук
Республики Татарстан

Г. И. Уляшева
председатель Татарстанского республиканского
отделения МОДИ "Исследователь"

Казань, 26 февраля 2021 г.



Государственное бюджетное научное учреждение
«Академия наук Республики Татарстан»

Татарстанское республиканское отделение
Межрегионального общественного движения
творческих педагогов «Исследователь»

Центр повышения квалификации АН РТ

БЛАГОДАРСТВЕННОЕ
ПИСЬМО

Академия наук Республики Татарстан и Татарстанское республиканское
отделение Межрегионального общественного движения
творческих педагогов «Исследователь»
выражают благодарность

Салаховой Илюсе Адиповне,
учителю татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия №90»

за подготовку лауреата регионального этапа
Всероссийского конкурса юношеских исследовательских работ учащихся
8-11-х классов им. В.И. Вернадского.
Желаем творческих успехов в профессиональной деятельности и
надеемся на дальнейшее сотрудничество!

М. Х. Салахов
президент Академии наук
Республики Татарстан

Г. И. Уляшева
председатель Татарстанского республиканского
отделения МОДИ "Исследователь"

г.Казань, 26 февраля 2021 года

**"Сөйләшсәк тә төрле телләрдә" бәйгесе.**











